

Сугышнын беренче коненнән ук Дубенка районы Ломат авылыннан 300 артык кеше дошманга каршы корәшергә киткән: шул исәптән Калимулла Сибгатулла улы Теминдяров, Абдулкадир Рәхмәтулла улы Насыров.... Аларнын һәрберсе хәтердә. Булган мәгълумат, башка батырлар белән бергә, Ломат авылы музеенда саклана. Кайберсе белән сезне дә таныштырып китәргә булдым. Бу материаллар Ломат авылы музенннан алынды.       Боек Ватан сугышы башланганда Абдулкадир Рәхмәтулла улы Насыров армиядә хезмәт итә була. Алдан артиллерия училищесы vтеп, Белоруссиядәге 455нче артиллерия полкына килеп житкән була. Боек Ватан сугышын ул биредә каршы ала. Боек Ватан сугышынын коточкыч икәнлеген без укып та, фильмнардан карап та, шахитларнын истәлекләреннән дә беләбез. Котелмәгән тизлек белән башкалабызга юнәлгән фашистларны жибәрмәv максаты белән, армияләрне Мәскәv тирәсенә туплыйлар һәм язма героебыз полкын Болоруссиядән Мәскәv олкәсенә кvчереләләр. Шунда каты яралана артиллерист А.Р.Насыров һәм ярты елга якын Калинин шәһәре госпиталендә дәвалана. Дәваланып чыккач, Калининдагы хәрби-политик училищесында белем ала һәм 1943нче елнын августында 232нче артиллерия девизиясенә жибәрелә. Курск-Орел сугышында корәшә; Украинанын авыл һәм шәһәрләрен дошманнан азат итә. Сума шәһәрен азат итvдә катнашкан, Украина армиясе белән бергә Днепрны кичкән, Киевны азат иткән. Шуна дивизияләре Сумско-Киевский дип атала башлый.
Киевны дошманнан азат итvдә кvр-сәткән батырлыгы очен Абдулкадир Рәхмәтулла улы Насыров Кызыл Йол-дыз ордены белән бvләкләнә.

